СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы Тау,423181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Тубылгы Тау авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2021 елның 21 гыйнваре № 7-17

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 ноябрендәге 18-46 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 ноябрендәге 18-46 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 30 статьяның 1.2 пункты җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрларын яңа редакциядә укырга:

- торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый);

- бакчачылык өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 400 кв. м; максималь 2000 кв. м; (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый);

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның башка хокукында булырга мөмкин булган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданының максималь күләме ике гектарга, шул исәптән торак пункт чикләрендә бер гектарга тиң (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый);

- 30 статьяның 4.2 пункты җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалану рөхсәт ителгәннең иң чик күләмнәрен участок күләмен яңа редакциядә укырга:

- торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый);

- блокланган торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый).

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 декабрендәге 19-49 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында «2012 елның 19 ноябрендәге 18-46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының Законлылык, табигатьне саклау, җирдән файдалану һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмагилов